# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№8 (708) 24 апрель 2020 ел (1441, Рамазан) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2020 ел - ТАССР төзелүгә 100 ел, Татарстанда Туган тел елы*

## ТУРЫ ЮЛНЫ ТАПКАННАРГА



Һәрнәрсәне бар иткән вә безне гүзәл сурәттә яратып, гакыл нигъмәте бүләк иткән мәрхәмәтле Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә ихлас белән коллык итегез, ата-ана вә остазларыгыздан артык мәхәббәт белән боерыкларын җиренә җиткерергә тырышыгыз! Коллык димәктән, кенозын намаз уку вә зикер әйтү, яки барлык эшләрне бер тарафка куеп, мәчет вә тәкияләрдә яту вә яки зиратларга йөрү, дип аңламыйча, бәлки Аллаһы Тәгаләнең боерган юлы белән өстендә булган бурычларны үтәү, халык белән гүзәл мөгамәләдә булу, рәхмәтле вә шәфкатьле булу һәм гөнаһлардан саклану, дип аңлагыз вә шулай гамәл итегез! Хөрмәтле Рәсүлулла китергән мөбарәк ислам шәригатенә үз башыгыз белән бер хәреф арттырмагыз вә бер хәреф киметмәгез; бер хәреф арттырган вә бер хәреф киметүдә булган затларга һич иярмәгез. Бәхет исә — саф шәригатьтәдер, моны һәрвакытта хәтерегездә тотыгыз! Киемнәрегезне, тәннәрегезне кер вә пычраклардан пакьләгән кебек, күңелегезне дә икейөзлелек, алдау, үч тоту, көнчелек, ачу, золым кебек бозык холыклардан пакь итегез! Ураза тоткан вакытыгызда, нәфесне тәрбияләү, сабыр итүгә гадәтләндерү, фәкыйрь вә мескеннәр хәлен сынап карауны ният итегез! Малыгыздан зәкят биргән вакытыгызда, юмартлыкка гадәтләнү, саранлык кебек бозык холыктан нәфесне сафландыру, фәкыйрьләрне шатландыру кебек изге нияттә булыгыз! Ислам кардәшләре белән танышу, мәшәкатьләргә гадәтләнү, сәяхәт итеп гыйбрәтләнү нияте белән — фарыз булган хаҗ сәфәренә барыгыз! Пәйгамбәрләр (аларга Аллаһы Тәгаләнең хәерле догасы һәм сәламе булсын!) — бабаларыбызны хак юлга өндәр өчен Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән җибәрелгәннәр һәм барысы да Аллаһы Тәгаләнең хак илчеләре вә гөнаһтан пакь бәндәләре булганлыктан, барысын да чын күңелдән сөегез! Мөбарәк динебез бу дөньядан ахирәткә барачак туры юлыбыз, хәсрәтле вакытларда астына кереп сыеначак җиребез, мәшәкатьләрдә рәхәт күрәчәк ярдәмчебез, барлык куркынычларда өмет итәчәк урыныбыз булганлыктан, һәрвакыт аңа ныгытып ябышыгыз! Савап вә газаплар, файда вә зарарлар, барлык гамәлләреннән безгә һәрвакыт хәбәр биреп торуда булган туры юл күрсәтүчебез, Изге Коръәннең хак вә хөрмәтле китап икәнлегенә ныгытып ышаныгыз!

**(Риза ФӘХРЕДДИН. "Әхлак гыйлеме"ннән)**

## ЧАЛЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

10 нчы апрель, изге җомга көнендә, Татарстан мәчетләре имамнары бөтен дөнья мөселманнары белән берлектә эпидемия нисбәтеннән гомум дога кылды. Әнә шул рәвешле, кешелек дөньясы өстендә үлемгә китерүче зәхмәт авыру — коронавирус инфекциясе таралуга бәйле рәвештә, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Казахстан мөфтиятенең башлангычына — планетаның барлык почмакларында бер үк вакытта дога кылуга кушылды. Әлеге чарада Чаллы шәһәре мөхтәсибәте дә катнашты. Шәһәребез мәчетләрендә өйлә намазыннан соң, бөтен татарстанлыларга һәм мөселманнарга Раббыбызның ярдәме, рәхмәте, иминлеге һәм шифасы килүен сорап, дога кылдылар. Дин кардәшләребезне доганы калдырмаска һәм түбәндәге сүзләрне кабатларга чакырабыз (укылышы): "Аллаһүммә инни әгузу бикә минәл барасы, вәл җүнүни, вәл җүзами, вә мин сайи-ил әскам".

Мәгънәсе: «Раббым, мин Синнән махау авыруыннан (проказа), акылсызлыктан, лепра чиреннән (хроник инфекцион авыру) һәм начар авырулардан саклавыңны сорыйм".

***




Коронавирус инфекциясе таралу куркынычы сәбәпле карантин игълан ителгәч, мәчетләрдә укулар үткәрү тыелды. Чаллы шәһәре мөхтәсибәте онлайн дәресләр уздыра башлады. Instagram социаль челтәрендәге каналыбызда (@islamchally) туры эфирда барган дәресләрне шәһәребез имамнары көн саен кичке сәгать 7 дә алып бара. Атнаның һәр көнендә аерым тема буенча белем бирелә: дүшәмбе – зекер, сишәмбе – гаилә, чәршәмбе – сира, пәнҗешәмбе – фикх, җомга – тәфсир, шимбә – имамнар тормышы, якшәмбе – хәләл темасы. Әлеге мөмкинчелекне халык та сөенеп һәм кызыксынып каршы алды – online рәвештә белем алырга көн саен якынча 60-70 кеше җыела һәм дәрестә актив катнаша, сораулар бирә, рәхмәтләрен юллый. Дәресләрне Рамазан ае азагына чаклы төгәл алып бару ният ителде. Әмма аннан соң да дәвам итү мөмкинлеге кире кагылмый.

**Нияз ГАЗИЗОВ**

## УРАЗА - ШӨКЕР ИТҮ ЧАРАСЫ



Уразаның канунлаштырылуында шактый хикмәтләр бар. Ураза – бирелгән нигъмәтләр өчен шөкер итү чарасы. Нигъмәтләр өчен шөкер итү акыл белән дә, шәригать буенча да фарыз. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә ураза турындагы аятьтә: «Шаять, Аллаһка шөкер итәрсез!» - дип әмер итеп, шуңа ишарәләгән. Ураза фәкыйрьләргә мәрхәмәтле һәм шәфкатьле булырга өйрәтә. Байларга ел буе ач торган фәкыйрьләрнең хәленә төшенергә ярдәм итә. Уразаның рухи саваплары, гөнаһлардан саклану кебек фазыйләтләре дә бар, гәүдәне чистарту (арындыру) һәм кайбер хасталыклардан саклау кебек матди файдалары да бар. Уразаның ашказанын сәламәтләндерүе һәркемгә мәгълүм. Әбү Һурайрадан (р.г.) риваять ителгәнчә, бер хәдистә Рәсүлүллаһ (с.г.в.): «Ураза тотыгыз, сәламәт булыгыз», – дип әмер иткән. Раббыбыз «Бәкара» сүрәсенең 21 нче аятендә: «Әй, кешеләр! Сезне һәм сездән элек булган кешеләрне халык кылучы Аллаһка гыйбадәт кылыгыз! Аллаһ газабыннан куркучы булу өчен», – дип әмер иткән.

Ураза турындагы аятьтә дә: «Әй, мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки уразага кимчелек китерүдән сакланырсыз!» – дип боерылган («Бәкара» сүрәсе, 183 нче аять).

Бу аятьләрдән аңлашылганча, барлык гыйбадәтләрнең дә, бигрәк тә, уразаның дәвамлы булуыннан тәкъвалык барлыкка килә. Ягъни барлык гыйбадәтләрне дә дәвамлы башкарган кеше тәкъвалыкка (Аллаһтан куркуга, Аллаһны ихтирам итүгә) ирешә. Димәк, гыйбадәт кылмаган кешеләр тәкъва булмый. Чөнки тәкъва – гыйбадәтнең нәтиҗәсе. Бигрәк тә бу аятьләрдән тәкъвалыкка ирештермәгән ураза һәм башка гыйбадәтләрнең Аллаһ каршысында рөхсәт ителмәве аңлашыла.

Ураза тотучы кешегә, дөнья һәм ахирәтен югалтмау өчен, әдәп сакларга, уразасын күрсәтмәләлектән һәм кеше сүзеннән сакларга, барлык гыйбадәтләрен дә тиешенчә үтәргә кирәк. Чөнки Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кылынмаган, бары тик кешеләргә күрсәтү өчен генә эшләнгән гамәлләр бик күп газапларга дучар итәләр.

Рәсүлуллаһның (с.г.в.) догасын китерәбез: «Әй, Аллаһым! Телемне ялганнан, йөрәгемне икейөзлелектән, гамәлләремне риядан (кешеләргә күрсәтү өчен эшләүдән) һәм күзләремне хыянәтле караудан пакълә! Чөнки Син күзләрнең хыянәтен һәм йөрәкләрнең серен беләсең!» (Зәбиди, «Итхаф», 7/514; Хатыйб, 5/268; Мишкәт, №2501).

**(ТР МДН сайтыннан)**

# ФИЛ ВАКЫЙГАСЫ

***Кадерле дин кардәшләрем!***

***Бүгенге хөтбәдә без сезнең белән тарихта тирән эз калдырган бөек шәхес, кешелек җәмгыятен үлем һәлакәтеннән коткаручы - Пәйгамбәребез (с.г.в.) турында сүзебезне дәвам итәрбез.***

Узган хөтбәләрнең берсендә ул килгәнче дөньяның нинди хәлдә булуын белдек. Ә бүген исә пәйгамбәр туар алдыннан гаҗәп вә мөһим вакыйгалар булып үтүен һәм гүя бу вакыйгаларның пәйгамбәр киләчәген хәбәр итүче билгеләр булуын күрербез.

Шул билгеләрнең беренчесе - Зәм-зәм коесы. Зәм-зәм коесы Пәйгамбәребез (с.г.в.) исеме белән тыгыз бәйләнгән. Бу коены аның бабаларының бабасы - Исмәгыйль (г.с.) нәселенә мирас итеп калдырган. Зәм-зәм кораеш кавеме өчен зур әһәмияткә ия. Чөнки аның җир астыннан чыгуы белән Мәккә шәһәре барлыкка килгән дип әйтергә була. Ул моңарчы беркем яшәмәгән җирне тергезгән, җанландырып җибәргән. Кораешлар Зәм-зәм суының ачлыктан, сусаудан интеккән баланы үлем кочагыннан алып калуын бик яхшы хәтерлиләр. Бу бала - пәйгамбәр Исмәгыйль (г.с.) була. Шуңа күрә кораешлар элек-электән Зәм-зәм коесын бик каты хөрмәт иткәннәр. Әмма вакытлар узу белән, ике арадагы сугышлар аркасында ул югалган, чөнки бер кавем аны таба алмаслык итеп ком белән күмеп куйган.

Җәмәгать, нәкъ Пәйгамбәрбез (с.г.в.) туар алдыннан гына аның бабасы Габделмоталлиб (шулай ук аны Шейба дип тә атыйлар) хикмәтле бер төш күрә. Төшендә аның янына ир кеше килеп: "Тәйбәне казып чыгар!" - ди. (Тәйбә - яхшы дигәнне аңлата). Уянып китә дә: "Нәрсә соң ул Тәйбә?"- дип аптырый. Икенче көнне шул ук урында йокларга яткач, төшендә тагын бу кеше килеп: "Мәзнүнәне казып чыгар!" - ди. Уянгач, Габделмоталлиб: "Нәрсә ул мәзнүнә?" - дип аңлый алмыйча тора. Өченче көнне дә шул ук урынга йокларга яткач, төшендә бу ир кеше килеп: "Зәм-зәмне казып чыгар! Син аның суы белән хаҗиларны эчерерсең. Ул кырмыскалар оясы урнашкан җирдә, эчәге белән кан арасында булыр. Ул урынны ак карга чукыр" - ди. Иртән Габделмоталлиб киркә белән көрәген ала да, Харис исемле улын ияртеп, Кәгъбә янына юл тота. Төше - ачык төш, шуңа күрә ишеткән билгеләрне эзләргә тотына. Игътибар белән караса, кораешлар Исаф исемле потка корбан чалу өчен сыер алып килгәннәр. Суеп яткан җирләреннән, сыерлары ычкынып китә дә чаба башлый, һәм бераздан хәлсезләнеп егыла. Егылган урында кораешлар аның эчәгеләрен чыгаралар. Габделмоталлиб сискәнеп китә: "Ул эчәге белән кан арасында булыр", - дигән сүзләр исенә төшә. Чыннан да, сыерның каны белән эчәгеләре арасында күпмедер ара була. Әмма ара зур булганлыктан, каян казырга белми. Шуннан кырмыскалар оясын эзләп таба. Болары да зур гына территорияне биләп алганнар, каян казырга билгесез. Бераздан ап-ак альбинос карга җиргә куна һәм томшыгы белән Кәгъбәтулла каршындагы җирне чукый. Габделмоталлиб йөгереп килеп, киркә белән шул төшне казый башлый. Кораешлар аның Кәгъбәтулла каршында чокыр казуын күреп, аптырап калалар, аны тыярга телиләр. Ул Хариска аларны туктатып торырга куша, ә үзе тиз-тиз казый. Бераздан киркәсе ташка бәрә. Ул: "Аллаһу әкбәр!"- дип кычкырып җибәрә. Кораешлар йөгереп килеп җитәләр. Тагын бер тапкыр сугуы була, Зәм-зәм бәреп чыга. Алар: "Нәрсә бу?" - дип сорыйлар. Габделмоталлиб: "Зәм-зәм коесы", - дип җавап бирә. Кораешлар үз күзләре белән Кәгъбәне һәм аның каршындагы Зәм-зәмне күреп шаккаталар. Еракта алып килеп су эчергәннәре өчен хаҗилар алдында аларның дәрәҗәләре зур була, ә хәзер Кәгъбә алдында гына чишмә барлыкка килә. Алар Габделмоталлибка: "Зәм-зәм коесын без синең белән бер дәрәҗәдә файдаланачакбыз," - диләр. Ул: "Юк, аны мин казып чыгардым", - дип җавап бирә. Шуннан бәхәс башлана, әздән генә сугышмый калалар. Нәтиҗәдә бәхәсне чишү өчен, дөяләренә атланып, Ясрибтә яшәүче сихерче хатынга чыгып китәләр. Юлда барганда ашарга ризыклары, эчәргә сулары калмый. Шулкадәр авыр була, хәтта бераздан үләчәкләрен аңлап алалар. Үлә калсалар, күмәргә җайлы булсын өчен, Габделмоталлиб һәрберсенә чокыр казырга куша. Чокыр казыгач, шунда төшеп утыралар. Бераздан Габделмоталлиб: "Мин барыбер су эзләргә кирәк дип уйлыйм", - дип, дөясенә менеп утыруы була, дөясе тоягы белән җиргә бәрә, һәм аның тоягы астыннан чиста су бәреп чыга. Ул: "Монда килегез, эчегез, үзегез белән су алыгыз", - дип калганнарны үзенә чакыра. Шунда гына кораешлар төшенәләр: Аллаһы Тәгалә бу җирдә чишмәне аңа биреп коткара аларны, димәк, Зәм-зәмне дә Габделмоталлибка биргән.

("Хаклыкта Кем сине монда эчерсә, шул Мәккәдә сине Зәм-зәм белән эчерүче"). Алар: "Безнең белән булган хәл чын могҗизадыр, Зәм-зәм тулысынча синеке. Без аңа дәгъва кылмыйбыз", - диләр. Аннан Мәккәгә кайталар. Шул көннән башлап кое өчен Габделмоталлиб җаваплы була. Ул Зәм-зәм белән хаҗиларны һәм калганнарны эчерә башлый. Кешеләр арасында Зәм-зәмне Габделмоталлиб коесы дип тә йөртә башлыйлар.

Карагыз, җәмәгать, Исмәгыйль пәйгамбәрдән мирас булып калган Зәм-зәм коесын пәйгамбәребезнең бабасы Габделмоталлиб эзләп таба. Бу кое аша Аллаһы Тәгалә Исмәгыйль (г.с.) белән Мөхәммәд (с.г.в.)нең бәйләнешен күрсәтергә тели...

Пәйгамбәр (с.г.в.) туар алдыннан икенче бер мөһим вакыйга була - Фил вакыйгасы. Мөгаен, Әбраханың бик зур гаскәр белән Мәккәгә Кәгъбәтуллаһны җимерергә килүе иң мөһим вакыйгадыр. Бу турыда сүзебезне башлаганчы, беренчедән, ул вакытта гарәпләрдә исәп-хисап вакыты булмавын искәртеп үтәсе килә. Алар вакыт берәмлеген нинди дә булса вакыйгага нигезләнеп истә калдыра торган булганнар. Мәсәлән, Фил елы, яки нинди дә булса вакыйга булган ел. Аллаһы Тәгалә, истә калдырсыннар өчен, Пәйгамбәрбез (с.г.в.) туган елны Әбраханың Мәккәгә Кәгъбәне җимерергә килү вакыйгасы, ягъни Фил вакыйгасы белән бәйләгән. Пәйгамбәрбез (с.г.в.) кайчан туган дип сорасалар, ул Фил елында туган дип җавап бирәбез.

Икенчедән, Аллаһы Тәгалә Үзенең йортын һәрвакыт саклавын күрсәтә, хәтта Үзенә якынрак коллары җимерергә теләсә дә, Ул моңа юл куймас. кораешлар мәҗүсиләр, ә Әбраха христиан диненнән. Әбраханың мәҗүсиләргә караганда хакыйкатькә якынрак булуына карамастан, Аллаһы Тәгалә аның үзен дә, гаскәрен дә кошлар җибәреп тар-мар итеп бетерә, чөнки ул Аллаһ йортын җимерергә тели. Аллаһ Тәгалә беркемгә, хәтта Үзенең яраткан колларына да, Аның йортын җимерергә ирек бирмәс, аларны Әбраханы тар-мар иткән кебек һәлак итәр.

Кадерле дин кардәшләрем, ул вакытта Африка территориясендә Ахбаш дип аталган көчле дәүләт була. Алар 60 мең кешедән торган гаять зур армияне Йәмәнгә җибәрәләр. Бу армия Әбраха командованиесе астында, Йәмән ярларына җитеп, тулысынча аны үз контроленә ала. Шуннан соң Әбраха Сан'а шәһәрендә әл-Каллис дип аталган хәтәр зур чиркәү төзергә һәм гарәпләрнең шунда хаҗ кылуларын тели. Әмма аларның Мәккәдәге Кәгъбәтуллаһка хаҗ кылуларын белеп ала, һәм Кәгъбәне җимерәм дип Аллаһ белән ант итә. Шуннан армиясен һәм Кәгъбәне җимерер өчен галәмәт зур филен әзерләп юлга чыга. Гарәпләр арасында: Әбраха Кәгъбәне җимерергә тели, дигән хәбәр тарала. Әбрахага Химьяр Зуннафар кавеме каршы чыга. Алар аны туктатырга телиләр, әмма бәрелештә Әбраха җиңә һәм Зүнәфәрне гаскәре белән әсирлеккә төшерә. Зүнәфәрне үтерергә теләгәч, тегесе: "Син мине үтермә, минем сиңа кирәгем чыгар", - ди. Шулай итеп ул исән кала. Аннан Әбраха гаскәренә каршы хас'амиин кавеме чыга, аларны да җиңәләр. Таифка барып җиткәч, Таиф башлыгы: "Без синең Кәгъбәне җимерергә теләвеңә каршы түгел, чөнки без Ләт вә'уззегә табынабыз. Моннан тыш без сиңа Мәккәгә юлны күрсәтер һәм Кәгъбәне җимерергә булышыр өчен кешеләр дә бирәбез", - дип каршы ала.

Карагыз, җәмәгать, Әбрахадан ничек курыкканнар һәм аңа буйсынганнар. Шулай итеп, Әбү Ригаль исемле кешене юл күрсәтүче итеп җибәрәләр. Алар Мәккәгә, дөресрәге, Мәгмәс дип аталган җиргә килеп җитәләр. Анда җиткәч, Әбү Ригаль үлә һәм аны шунда җирлиләр. Бераздан гарәпләр аның каберен ташлар атып томалап бетерәләр, чөнки ул Әбрахага Кәгъбәнең кайда икәнлеген күрсәтүче. Армиясе килеп җиткәч, Әбраха, анда булган бөтен кыйммәтле әйберләрне җыеп алсын өчен, Әсәд исемле хәрби башлыкларының берсен Мәккәгә кертеп җибәрә. Ул шулай эшли дә, булган бөтен кыйммәтле нәрсәләрне, бик күп дөяләрне, шул исәптән Габделмоталлибның 200 дөясен алып чыга. Күпмедер вакытлар узгач, Әбраха Мәккәнең иң дәрәҗәле кешесен табып, аларның монда сугышырга түгел, ә бары тик Кәгъбәне җимерергә килүләрен хәбәр итсен өчен, Хәнәтәтәне шәһәргә җибәрә. Хәнәтәтә, Мәккәгә кергәч, пәйгамбәребезнең бабасы Габделмоталлибны очрата һәм: "Сез сугыш башларга теләмәсәгез, безнең хаким дә сугышырга теләми, ә бары тик Кәгъбәне җимерергә килүен хәбәр итеп мине сезгә җибәрде", - ди. Габделмоталлиб: "Аллаһ белән ант итеп әйтәм, без сугышмаячакбыз. Чөнки бу йортның Раббысы бар, Ул аны Үзе саклый", - дип җавап бирә. Аннан: "Мине үзеңнең патшаңа алып бар", - ди.

Ул Әбрахага керер алдыннан әсир Зүнәфәрне күреп ала һәм: "Әй, Зүнәфәр, син безгә ярдәм итә алмыйсыңмыни?" - ди. Ул: "Үлемен көтүче кеше ничек ярдәм итә алсын. Әмма мин сиңа халкың арасында синең югары дәрәҗәгә ия икәнеңне хәбәр итсен һәм Әбраха белән сөйләшү оештырсын өчен филне алып баручы Унейсага мөрәҗәгать итәргә киңәш итәм," - дип җавап бирә. Габделмоталлиб аның киңәшен тота. Унейса, Әбраха янына кереп, Габделмоталлиб турында сөйли. "Бу кеше Кәгъбә каршындагы Зәм-зәм коесын казучы һәм аның суы белән хаҗиларны эчерүче," - дип өсти. Әбраха боларны ишеткәч, Габделмоталлибны хөрмәт итә башлый һәм үзенә керергә рөхсәт бирә. Аның үзен, матур, мөлаем кыяфәтен, дәрәҗәсен күргәч, тагын да ныграк хөрмәт итә башлый. Хөрмәт йөзеннән, тәхетеннән төшеп аның янына утыра. Шунда Габделмоталлиб аңа: "И падишаһ, син минем 200 дөямне тартып алдың бит", - ди. Моңа каршы Әбраха: "Мин сине күрү белән бик каты хөрмәт итә башладым, ә бу сүзләрне ишеткәч, сиңа нәфрәтем уянды", - ди. Габделмоталлиб: "Ни өчен?" - дип сорагач, Әбраха: "Мин синең динеңне, бабаңнар дине йортын җимерергә килдем, ә син миннән 200 дөя сорап ятасың", - дип җавап бирә. Габделмоталлиб: "Мин бары тик дөяләрнең хуҗасы, ә бу йортның Үз Хуҗасы бар. Ул Үзенең йортын Үзе кайгырта", - дип җавап бирә. Шуннан Әбраха Габделмоталлибка дөяләрен кайтарырга һәм монда сугышырга килмәвен, ә Кәгъбәне җимерергә килүен хәбәр итәргә боера. Габделмоталлиб, кораешлар янына кайткач: "Тауларга таралыгыз. Әбраха Кәгъбәне җимергәч китәчәк", - ди. Шулай итеп кораешлар Мәккәдән чыгып, тауларга менеп китәләр. Габделмоталлиб Кәгъбәтуллаһ ишеге янында туктап: "Кол бары тик үзенең көтүен генә кайгырта ала, шулай булгач Үзеңнең йортыңны саклачы. Аларның тәресе Синең мөкатдәс урыныңны алмасын. Әгәр Син моңа юл куеп, безне калдырсаң, бу Син теләгәнчә булыр", - ди. Шуннан соң Кәгъбәне калдырып, ни булачагын күзәтү өчен, тауга менеп китә. Әбраха үзенең армиясе белән Мәккәгә керә, җимерсен өчен филне Кәгъбәгә таба юнәлтә, ә фил атларга да теләми. Аңа суга, кыйный башлыйлар, әмма фил селкемни дә. Йәмән ягына каратып бастырсалар, ул йөгерергә тотына, ә Кәгъбәгә боруга, шып утыра, бер адым атламый. Берзаман Кәгъбәгә борырга тырышканда фил ычкынып китә дә, якындагы тауларга таба чаба. Шулвакыт һавада кап-кара болытлар пәйда була. Бу - болытлар түгел, ә диңгез ягыннан очып килүче кошлар көтүе була. Һәр кош өчәр таш тоткан, берсе томшыкларында булса, икешәрне тәпиләренә алганнар. Кошлар армия өстенә җиткәч, ташларын җиргә ташлыйлар. Болар гади ташлар түгел, ә җәһәннәм утында кыздырылган ташлар. Кешегә эләгү белән аның тәнендәге ите чын мәгънәсендә эри башлый. Әбраханың гаскәре күз алдында таркала һәм үлә башлый, төрлесе төрле якка йөгерергә тотына, ә Әбраха үзе берничә гаскәре белән качып котылырга өлгерә. Йәмәнгә кергәндә аның кыяфәте коточкыч була, аның турында: "Ул кош баласына охшаган иде", - диләр. Әбраха озак яши алмый, тиздән үлә.

Бөек Аллаһы Тәгалә Үзенең Китабында бу вакыйга турында безнең исебезгә төшерә: "Син Раббыңның фил ияләрен ничек җәзалавын күрмәдеңме әллә? Ул аларның мәкер эшләрен бутап, өсләренә көтүе-көтүе белән кошларны җибәрмәдемени? Кошлар аларның өсләренә кыздырылган балчыктан ташлар аттылар һәм аларны киптерелгән, чәйнәлгән салам яфраклары кебек калдырдылар".

Бу вакыйга, ягъни Аллаһның нинди зур армияне тар-мар итү вакыйгасы бөтен гарәпләргә ишетелә. Һәм бу елны Фил елы дип атый башлыйлар.

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ, Чаллының "Тәүбә" мәчете имам-хатыйбы**

## Ураза – кызулыктан саклану

Аллаһы Тәгалә уразаны – ашау, эчүдән һәм якынлык кылудан тыелып торуны – бар халыкларга да кушты. Нинди милләт, нинди кавем, нинди диндә булуына карамастан, уразада булу – тыелып тору тиеш. Коръәндә махсус ураза аятьләре бар. Гомумән, уразаның файдасы, кешегә уңай тәэсире турында күп сөйләнә, күп языла. Табиблар аның кеше тәненә сихәте турында сөйләсә, диетологлар уразаның симерүдән саклавын, аның чистарту үзенчәлегенә ия булуына игътибар итә, психологлар уразаның кеше эмоцияләренә тәэсире, кеше хисләрен тотрыкландырудагы әһәмиятен күрсәтәләр, экономистлар уразада экономия күрә, әхлак сагында торучылар уразаның әхлак тәрбияләүдәге мөмкинлеген билгеләде.

Һәрбер дин уразаның үзләрендә кабул ителгән вариантларын куллана. Дөньяви яктан да аның төрле төрләре бар. Максатыбыз уразаны ничек тоту, ничек булырга тиешлеге турында түгел. Ә ураза турында уйлану, фикерләү. Ураза хакындагы мәгълүматны Коръәннән укып беләбез, шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең сөннәтендә ислам динендәге уразаның хасияте турында төгәлләштереп бирелә. Хәдисләр белән ныгытыла.

Ураза Рамазан аенда тотыла. Рамазан сүзенең сүзлектәге мәгънәләренә игътибар итсәк, “кызулык” төшенчәсен белдерә. Кызулык исә эсселек, кызу булу, тизлек, ашыгу, ашыгучанлык, ярсу, ярсучанлыкны аңлата. Халык телендә мунчаның кызулыгы, көннең кызулыгы, яшьләрнең кызулыгы, кызулык белән эшләп ташлау, кызу канлы дип тә кулланыла. Инде килеп ашау-эчү, якынлык кылу кебек гамәлләрне кешенең энергиясе арту, кызулык өстәлү дип карасак, кешенең һәрдаим кызулык өстәп торуын чамалый алабыз. Салкында өшегән кеше ашап алса җылынып китә, кызулыгы арта. Ел буена кеше кызулык арттырып яши. Һәр нәрсәнең чамасы булган кебек, ел буена кызулык туплаган кешегә дә елына бер генә мәртәбә шул кызулыктан таң атканнан алып кояш баеганчыга хәтле тыелып тору мөмкинлеге бирелә. Рамазан аенда ураза тоту – тыелып тору – кызулыктан тыелып тору, кызулыгыбызны балански китерү мөмкинлеге бар. Шуңа да бу айда, тән кызулыгыннан, хисләр кайнарлыгыннан, “тел кайнарлыгыннан”, ачу-кызудан тыелып тору форсаты бирелә дип тә фикерләргә мөмкин.

**Гөлфия НАСЫЙБУЛЛИНА, Чаллы шәһәре**

### МИНЕМ ФИКЕР

**Рәис хәзрәт ӘХМӘТОВ, Чаллының “Сөембикә” мәчете имам-хатыйбы**



Безгә Аллаһ тарафыннан бирелгән шушы дөньябыз - сынау мәйданыдыр. Ә инде шушы сынауларны тиешенчә, Раббыбыз кушканча үтү безнең бурычыбыз. Кешелек дәвамында сынау булып күп афәтләр килгән, төрле чирләр, төрле бәла-казалар,сугышлар... Менә бүген дә Раббыбыз безгә зур сынау бирде. Чирләрдән куркып, өйләргә кереп бикләндек, урамга чыгарга куркабыз. Аллаһ бөтен дөньяны куркуга салды. Шулай Раббыбыз әйтә, Миннән генә куркыгыз, ди. Кардәшләрем, менә шулай, Раббыбыз дөнья эшләреннән арынып, уйларга, фикерләргә безгә бераз вакыт бирә. Аллаһ әйтә, балалар һәм дөнья сезне Миннән ераклаштыра, ди. Дөнья мәшәкатенә чумып, Аллаһны онытабыз. Менә үзенең нурлары белән рамазан аебыз житте, гөнаһларыбыз кичерелә, догаларыбыз кабул була, Аллаһның рәхмәтенә ирешә торган аебыз. Күбрәк гафу үтеник, күбрәк гыйбадәт кылыйк. Өйләрдә утырганда тормышыбызга нәтиҗә ясыйк. Аллаһ безгә форсат бирә уйларга. Күзебезне ачып, бераз тирә-якка карыйк: хаталарыбыз, ялгышларыбыз юк микән? Инде калебләребезне чистартырга менә шушы рамазан айларыбыз сәбәп булсын. Изге рамазан айлары белән, кардәшләрем!

## БАЛАЛАР ДА РАМАЗАННЫ КӨТӘ

Рамазан аен безнең гаиләбез бик көтеп ала, бу сүзләр бик гади булып яңгыраса да, аның эчендә күпме мәгънә ята! Бу изге аебызны без файда белән уздырабыз, ул безнең, ә инде иң мөһиме безнең балаларыбызның - безнең динебезне дәвам кылучыларның хәтирәләрендә бер җылы, могҗизалы вакыйга булып калыр дип өмет баглыйбыз...

Рамазан ае өебезгә аяк басу белән, без азан әйтәбез, гирляндаларны кабызабыз, шарларны инде алдан ук кабартып куябыз һәм бүләк алыр вакыт җитә... Безнең балаларыбыз (улларымның берсенә бернichә айдан биш, икенчесенә өч яшь тулачак, Алла боерса) бүләк актарган вакытта мин үзем, әни кеше буларак, йомшак тавышым белән мөнәҗәт җырларга яки Коръән китабыбыздан бернichә сүрә укып китәргә тырышам. Соңыннан гаиләбез белән җыелып, үләнле чәй янына тәм-томнар куеп, кичке чәй эчү мәҗлесен оештырабыз...

Инде ураза аеның беренче көненнән үк безнең “энергичный” аебыз башланып та китә! Бернichә ай алдан ук планнарны язып кую, фикерләрне туплау, бүләкләрне әзерләү көндәлек тормышны тәртипкә сала.

Балаларым белән төрле-төрле аппликацияләр ясыйбыз, төшке аштан соң Коръән укып алабыз, урамда, саф һавада рәсемнәр ясыйбыз, кошларга җим салабыз, төрле физик уеннар уйныйбыз, өйгә кергәч мавыктыргыч формада дәресләр өйрәнәбез. Ә инде авыз ачар алдыннан бергәләшеп ифтар табынын әзерлибез һәм ахшам намазына азан яңгырагач, гаиләбез белән сөннәт буенча су эчәбез яки финик белән авыз ачабыз. Минем программам буенча 30 көнгә әзерләп куелган конвертларым бар, алар гади түгел, сюрприз белән! Һәр көн, авыз ачканнан соң балаларым белән сюрприз алырга барабыз, бу - искиткеч мизгелләр...

Нәтиҗәдә шушы планнарым, язмаларым, сюрпризларым аркасында балаларым бүләкләр белән уйнаганда: “Әнием, хәтерендәме, без моны Рамазан аенда алдык!”- дип сөенечле авазларын яңгыраталар, ә мин, әни буларак, Аллаһыбыз каршында үз вазыйфамны җитди аңлап, аларны чиста, дуслык, гадел ислам динебезгә өндәүгә бер сәбәп булуым өчен ихластан сөенәм, шөкерләремне Раббыма кылам!

Рамазан ае узгач та бу айда җыелган күп файдалы видеоязмаларыбызны карап, сагыну хисләрен кичереп алабыз, күңелләребезгә рәхәт булып китә...

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА, Чаллы шәһәре**

### ӘДӘБИ СҮЗ

***Рәзинә МӨХИЯР***

## *Апрель җиле*

*Быелгы ел апрель җиле*
*Шомлы, үткен, бик куркыныч.*
*Кая китте елмаюлар,*
*Кайда хәзер рәхәт, тыныч?!*
*Җир шарында тик бер бәла...*
*Аты аның – таҗлы вирус.*
*Таралганын, талаганын*
*Күзәтәме соң Сириус?*
*Уйланамы Җирдә кеше*
*Афәтнең ни китергәнен.*
*Үзгәрәме, үртәләме,*
*Аңлап, туеп сикергәнен?*
*Тәүбәсенә киләме ул,*
*Бөек Заттан гафу сорап.*
*Хыяллары тирбәләме*
*Җайлы, җитеш тормыш юрап?*
*Өтелә дә, төртелә дә...*
*Кеше җаны шулай ныгый.*
*Көферлектән, көчсезлектән*
*Намус, вөҗдан җанны туный.*
*Фани дөнья өч көнлек тә...*
*Нәфес аты алдан чаба.*
*Дөньялыкта кем ни эзли,*
*Ахыр чиктә шуны таба.*

## *БЕЛӘСЕЗМЕ?*

Ураза гарәпчә «саум» дип атала. «Саум»ның лексик мәгънәсе «берәр нәрсәдән ерагаю, читләшү, берәр нәрсәгә каршы тору» дигәнне белдерә. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Мәрьям турында болай дип әйткән: «Мин Аллаһ ризалыгы өчен һичкем белән сөйләшмәскә нәзер әйттем, шуның өчен бу көндә һичкем белән сөйләшмим» («Мәрьям» сүрәсе, 26 нчы аять).

Уразаның шәригатьтә мәгънәсе ураза тотучы кешеләрнең үзләрен икенче фәҗердән (таң атканнан) алып кояш батканчыга кадәр ашау-эчүдән һәм җенси якынлыктан тыюларын белдерә. Икенче фәҗер – «имсак» вакыты. Гарәп телендә «имсак» үз-үзеңне тыю дигән мәгънәне белдерә. Имсак вакытында ястү намазының вакыты чыгып, иртәнге намазның вакыты керә. Шушы вакытта сәхәр ашалып бетеп, ураза башлана. Моннан соң ураза тотучы кеше үзен ашаудан да, эчүдән дә, җенси якынлыклардан да тыя.

Кояш баткан вакыт ифтар вакыты була. Бу вакыттан алып ураза тоткан кешеләр өчен тыелган нәрсәләр рөхсәт ителә. Ахшам намазының вакыты да кергән була. Имсак мофтыйрат (уразаны бозучы) дип аталган нәрсәләрдән нәфесне чынлыкта яки хөкем рәвешендә тыя. Ялгышып яки онытылып китеп берәр ризык алып капкан чакта хөкмән (хөкемле) имсак барлыкка килә һәм ураза бозылмый.

Имсакның капма-каршысы – ифтар. Бер дә ураза тотмау да – ифтар, уразадагы кешеләрнең, кояш баткач, авыз ачулары да ифтар була. Ураза тотканда уразаны бозарлык берәр нәрсә эшләү дә ифтар санала. Ифтар кылган кеше дә, уразаны бозган нәрсәләрнең һәркайсы да «мофтыйр» дип атала. Барысы бергә «мофтыйрат» дип исемләнә. Рамазан аен «Шәһри Сыйам» дип әйтәләр, Ураза бәйрәмен, тыелган вакыт тәмамланганга күрә, «Гайд әл-Фитыр» (ураза төгәлләнү бәйрәме) дип атыйлар.

**(ТР МДН мәгълүматларыннан)**

## КЫЛГАН ХАҖЫМ – АЛЛАҺ БИРГӘН ТАҖЫМ



*(Дәвамы. Башы газетаның алдагы саннарында)*

Мәдинә – пәйгамбәребез яшәгән, күмелгән шәһәр. Халык ташкыны туктаусыз хәрәкәттә. Пәйгамбәребез (с.г.в) күмелгән урын мәчетнең ап-ак биек манаралары арасында, яшел гөмбәз астында аерылып тора. Кабер үзе шушы мәчет эчендә. Пәйгамбәребезнең мөнбәре дә шушында. Булачак хаҗиларның һәммәсе пәйгамбәребез каберенә якынрак килергә тырыша, аңа сәлам бирә. Ул вакыттагы хис-кичерешләрне әйтеп-аңлатып бетерә торган түгел. Кунакханәгә кайтасы да килми. Һәркем мәчеткә ашыга. Үзенең бер хәдисендә пәйгамбәребез «Минем өем белән мөнбәрем арасында җәннәтнең бер бакчасы булыр», дигән. Әлеге бакча «Раудә» дип атала. Андагы келәмнең ишеннән эшләнгән намазлык та шулай.

– Раудә намазлыгын алыгыз, – диде җитәкчебез. – Бу намазлыкның төсе дә, исе дә башка. Мәккәдә бик кыйммәт. Ләкин безгә әлеге намазлыкның бөтен хикмәте пәйгамбәребез (с.г.в.) исеме белән бәйле булуында иде.

Мәдинәдәге илаһилык, тарихилык, андагы халәт шул намазлыкка сеңгән төсле тоелды. Бөтен барлыгы, булмышы белән җәннәтнең бер бакчасын хәтерләткән намазлыкны һәркем алырга тырышты. Ниятләп, атап. Туган авылым мәчетенә бүләк итү нияте белән мин дә алдым.

Мәдинәдә узган ике көн ярым вакытның һәр мизгеле исәптә, һәр мизгеле санаулы иде. Кунакханәгә кайтып ашый да, халык пәйгамбәребез мәчетенә ашыга. Җитәкчебез Тимергали хәзрәт Мәдинәнең һәр тарихи урынын күрсәтергә тырыша. Чөнки күпләребез өчен әлеге сәфәр беренче һәм соңгысы булырга мөмкин. Шәхсән үземә, Мәдинәдә генә түгел, мөселман дөньясында иң беренче булып төзелгән Куба мәчетендә булу исемдә калды. Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.) монда җәмәгать белән беренче җомга намазын укыган. Мәчетнең тышкы диварына пәйгамбәребезнең «Әлеге мәчеттә укыган бер намаз гомрәгә тиң» дигән хәдисе язылган. Пәйгамбәребезнең намаз укыган урыны да, якынча, билгеләп куелган. Әлбәттә инде, һәркем шул урында намаз укырга тырышты.

**Рәфкать ШАҺИЕВ, Әлмәт шәһәре.**

*(Дәвамы бар)*

## КҮҢЕЛ КҮЗЕН АЧЫП...

**Мәүлә** - хуҗа

**Мөкафәт** - хезмәт өчен бирелгән премия, бүләк

**Кәлимә** - сүз

**Җәридә** - газета

**Фикһ** - ислам дине турында белем

**Коръән китабында кайсы сүрә җимеш исеме белән атала?**

*“Инҗир” сүрәсе.*

**Мөселман кешесенең алтын киюе дөрес гамәлме?**

*Пәйгамбәребез (с.г.в.) алтын һәм ефәк хакында: “Болар өммәтемнең ирләренә - хәрам, хатын-кызларына хәләл булды”, - дигән.*

**Нинди дүрт нәрсә авыруга сабыштырыр?**

*Күп сөйләү, күп йоклау, күп ашау, күп ярату.*

**Нинди дүрт нәрсә байлык китерер?**

*Намаз уку, тәүбә итү, сәдака бирү, зекер итү.*

## Колак салсаң, үкенмәссең

***Аллаһ Раббыбызның яраткан колларыннан буласың килсә:***

* Изге эшләр эшлә. “Изгелекләр кылыгыз! Аллаһ изгелек кылучыларны ярата” («Бәкара» сүрәсе, 195 нче аять).

* Гөнаһлы гамәлләреңне калдыр, тәүбәгә кил. “Аллаһ тәүбә итеп тәәлүчеләрне яратадыр” («Бәкара» сүрәсе, 222 нче аять).

* Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) сөннәтенә ияреп, аны үзең өчен иң яхшы үрнәк буларак танып яшә. “Ий, Мөхәммәд, син аларга әйт: «Әгәр Аллаһны яратсагыз, миңа иярегез, миңа иярсәгез, Аллаһ та сезне яратыр” («Әлү-Гыймран» сүрәсе, 31 нче аять).

* Бөтен эшләреңдә дә Аллаһка тәвәккәл бул. “Аллаһ Үзенә тәвәккәл кылучыларны яратадыр” («Әлү-Гыймран» сүрәсе, 159 нчы аять).

* Гадел бул. “Аллаһ гадел булучыларны яратадыр” («Мәидә» сүрәсе, 42 нче аять).

* Тәкъва бул (ягъни Аллаһның әмерләренә буйсынып, тыелган эшләрдән ерак тор). “Аллаһ тәкъва булучыларны яратадыр” («Тәүбә» сүрәсе, 7 нче аять).

***Тәмле булсын!***

## Каражимеш белән пирог



Камыр өчен: 100 г өй җылылыгындагы каймак, 100 г өй җылылыгындагы ак май, 1 йомырка, 1 аш калагы шикәр комы, ярты чәй калагыннан әзрәк тоз, 1,5 чәй калагы коры чүпрә, он - кирәгенчә.

Эчлек өчен: 200 г төшсез каражимеш, 200 г каймак, 50 г куертылган ак сөт, 50 г әстерхан чикләвеге, 2 йомырка.

Эш барышы. Иң элек каражимешне җылымса суга салабыз да, йомшаргач, иттарткычтан үткәрәбез, әче булса шикәр комы салабыз, куе булса кайнаган су салып болгатып куябыз.

Барлык катнашмаларны салып камыр басабыз да, 15 минутка өстен ябып торабыз. Әзер камырны җәябез, майланган табага куябыз, каражимеш катнашмасын салабыз да җәябез. Йомырканы күпертәбез, каймак, сгущенка салабыз, болгатабыз. Шушы катнашманы каражимеш өстенә агызабыз. Өстенә чикләвек уып салабыз. Камырның чит-читләрен матур итеп ясыйбыз да мичкә пешерергә озатабыз. 200 градуслы мичтә 40 минутлап пешә.

**(Мәрьям Миңнегулова рецепты**

***Саулыгым - байлыгым***

## Ютәл борчыса...



Гап-гади томау да, төпкә төшеп, ютәл айлар буена сузылырга мөмкин. Менә шулчакта арзанлы гына чаралар ярдәмгә килә. Озакка сузылган ютәлдән коткаручы ысулларның берсе – камфара мае. Яңа кыйбатлы дарулар барлыкка килеп, бу дару хаксыз онытылды. Элек аны әбибабайларыбыз колак сызлаганнан, буыннар авыртканнан еш куллана торган иде. Ютәлдән котылу өчен кич йоклар алдыннан аркага, аеруча үпкә турысына сөртергә кирәк. Моны ике көнгә бер эшлиләр. Көн дә сөрткәндә, организмга авыррак булуы, йөрәккә бәрүе бар. Горчичниклар да хәзер онытылган һәм арзан чара. Алар шулай горчица маен су белән катнаштырганда барлыкка килә торган кислота тирәлеге хисабына тирене ярсытып, “яндыру” эффектын тудыра. Аларны шулай ук йоклар алдыннан аркага ике көнгә бер кую яхшы эффект бирә. Бер чынаяк сөтне кайнатып, берәр бал кашыгы аш содасы һәм бал салып, кайнаррак килеш эчеп, төренеп ятсагыз, файдасын бик тиз сизәрсез. Бер чынаяк сөткә зур булмаган бер баш суганны турап, кайнатып чыгарып эчү дә ютәлдән коткара ала. Андыз тамырының озакка сузылган ютәлдән шулай ук файдасы бар.

**Дилбәр Сөләйманова киңәшләре.**

**(Фотолар интернеттан алынды)**

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**24 апрель 16 сәг.**
**фактта 24 апрель 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**